**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

18.06.2018 № 257

# КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 31 нче маеннан 225 нче санлы “Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бүлегенең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында яңа редакцияне раслау турында” гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 31 нче маенда кабул ителгән 225 нче санлы “Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдә админстратив регламентларга үзгәрешләр кертүче яңа басманы раслау хакында” гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертә:

- Җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентының “Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты” исемле 2 нче бүлегендә 2.4 пунктын 1 нче кушымтагы басма нигезендә үзгәртеп язарга.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасының “ Интернет” челтәрендәге хокукый мәгълүматлар рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольләүне үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне тәгаенләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәк булуын истә тотып, Россия Федерациясе кануннары буенча туктатып тору мөмкин булса муниципаль хезмәт күрсәтүне кирәк булган очракта туктатып торуның срогы | Гаризаны теркәүдән соң 14 көн эчендә.<br><br>Элек расланылган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы дубликатын бирү гариза кабул ителгәннән соң 4 көн эчендә, ләкин 10 календарь көннән дә артмаган вакыт эчендә бирелә.<br><br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне кичектерү каралмаган | РФ ГрК 6 өлеше, 57 бит |

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең срогы тормышка ашыру өчен кирәк булган административ процедураларның минималь вакыты суммасын исәпләп билгеләнде.